**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Яңа Чыршылы авыл җирлеге**
**Кузайкино авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2021 елның 20 ноябре

№ 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Кузайкино авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы авыл җирлеге Кузайкино авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлеге Кузайкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче төркем инвалидлардан тыш, 1500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы авылы, Заречная, 25, Центральная, 12А буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Чыршылы авыл җирлеге башлыгы  Р.Ә. Мөхәмәтшина